Татар мәктәбендә укучы балаларга
татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
4 нче сыйныф
2016-2017 уку елы

**Үткәрү вакыты- 60 минут**
**Максималь балл – *44***

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Калын сузыклардан гына торган мәкальне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Курыккан эт койрыгын кысар.

ә) Батыр үз халкын яклый.

б) Батырларга юл туры.

в)Тәвәккәлгә бүре тимәс.

2. Тартык авазлардан гына торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а)[ы], [т], [н], [п], [й], [с];

ә)[д], [з], [ч], [ф], [х], [й];

б)[р], [г], [ш], [у], [и], [й];

в) [и], [п], [в], [й], [ү], [ә].

3.Ябык иҗекләрдән генә торган сүзләр күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) таш, кабак, билге;

ә) кыяр, чөгендер, дүрт;

б) китап, дәфтәр, өстәл;

в) туфрак, өстәл, кул.

4.***Чикләвекләр*** сүзенең тамыры дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) чи;

ә) чик;

б) чиклә;

в) чикләвек.

5. Антоним парлар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) юмарт – саран, авыр – җиңел;

ә)кыйбат – арзан, таза – юан;

б)начар – яхшы, зур – биек;

в) коры – юеш, акыллы – белемле.

6. Күчерелмә мәгънәдәге сүзе булган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Безнең якларда урманнар бик күп.

ә) Туйганчы көмеш чишмә суын эчтек.

б)Койма буйларында үскән ромашка чәчәкләрен җыйдым.

в)  Без кышкы урманны яратабыз.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килешен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Кул* ***кулны*** *юар, ике кул* ***битне*** *юар.* (Мәкаль)

а) баш килеш;

ә) төшем килеше;

б) чыгыш килеше;

в) урын-вакыт килеше.

8.Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Зур елгалар вак чишмәләрдән башлана бит. (М.Хуҗин);

ә) Көчле җил кузгалды, һәм яңгыр ява башлады. (Г.Галиев);

б) Кояш, элеккедән дә матуррак булып, болыт астыннан килеп чыкты. (Г.Бакир):

в) Малай чәчәккә иелде, бик зур саклык белән аны учына алды. (М.Ханнанов).

9.Киләчәк заман хикәя фигыльнең беренче төре кулланылган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а)Галим уйлар, надан ышаныр. (Мәкаль);

ә)Сандугач үз җирендә сайрый. (Мәкаль);

б) Кеше кешесез яшәми. (Мәкаль);

в) Без иртәгә иптәшләребез белән экскурсиягә барачакбыз.

10. Кисәкчәләрдән генә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) шикелле, өчен, кадәр, чаклы;

ә) -кылт/-келт, -кылтым/-келтем, -сыл/-сел, -су;

б) ич, үк, кенә, иң, һич;

в)-лы/-ле, -даш/-дәш, -чан/-чән, -гы/-ге.

11. Җәенке җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Әтием – төзүче.

ә) Көн җылы.

б) Әтием, әнием – укытучылар.

в) Җылы көнне без рәхәтләнеп укыйбыз.

12.Җөмләнең төрен билгеләгез. ***(2 балл)***

*Никадәр изге, никадәр кадерле ул Туган ил!* (Р.Төхфәтуллин)

а) хикәя;

ә) боеру;

б) тойгылы;

в) сорау.

## II. Теоретик бирем.

Зат алмашлыклары турында языгыз. ***Ул*** алмашлыгын килешләр белән төрләндерегез. ***(10 балл)***

## III. Иҗади бирем.

Сүзләргә сузык авазлар өстәп, мәкальне укыгыз, шул тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. ***(10 балл)***

ТРШКН ТБР – ТШК КДК КГР.